# КАРАР № 61

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Яңа Шашы авыл җирлеге Советы утырышы

22 декабрь 2022 ел — Яңа Шашы авылы

**Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Советының 2019 нчы елның 25 октябрендәге 109 нчы номерлы «Җирле салымнар буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында»гы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты нигезендә, җирле салымнар, пенялар һәм әлеге салымнар буенча штрафлар буенча бурычларны түләүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында Яңа Шашы авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Советының 2019 елның 25 нче октябрендәге 109 нчы номерлы «Җирле салымнар буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 1 пунктның 2 абзацында «өч ел» сүзләрен “бер ел” сүзләренә алмаштырырга.

1.2. 1 нче пунктны түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

“- Россия Федерациясеннән читкә киткән физик затларда недоимка, пенялар һәм штрафлар буенча бурычлар булу, 3 елдан артык түләнгән бурычлары барлыкка килгәннән бирле, бурычлы кешенең мөлкәте булмаган очракта, аңа кире кайтару мөмкинлеге булырга мөмкин;

- өлкәннәр (ветераннар)йортларында яшәүче затларга недоимка, пенялар һәм штрафлар буенча бурычлар булу;
- суд карары нигезендә һәм иректән мәхрүм итү урыннарында булган чорга - иректән мәхрүм итү урыннарында булган затларның бурычлары, пенялары һәм штрафлары булу".
-

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб–адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Яңа Шашы авыл җирлеге башлыгы: М.С.Сабирҗанов